КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 июль г.Казань № 575

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2023 ел, 14 сентябрь, 1125 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 7 февраль, 66 нчы; 2024 ел, 4 март, 122 нче; 2024 ел, 2 апрель, 213 нче; 2024 ел, 11 апрель, 250 нче; 2024 ел, 22 апрель, 266 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда:

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.3. | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе | гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрү | 276 310 876,83 |
| | | фундаменталь фәнни тикшеренүләр үткәрү | 125 258 822,77 |
| | | мәдәни мирас объектларын саклап калуны һәм алардан файдалануны тәэмин итү | 25 946 470,43 |
| | | мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базаларын алып бару | 8 052 352,9 |
| | | фәнни-методик тәэмин итү | 10 736 470,52»; |

2.5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3.4. | «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе | мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базаларын алып бару | 10 102 353,72 |
| | | геодезия һәм картография эшләрен башкару | 2 832 846,28»; |

6.1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга һәм аларның күләмнәренә түбәндәге эчтәлекле 7 бүлек өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «7. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты учреждениеләре | | | | |
| 7.1. | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе | югары белем бирү буенча мәгариф программаларын – аспирантурада фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыру | 226 110,87 | 24,0 | белем алучылар саны, кеше |
| | | югары белем бирү буенча мәгариф программаларын – аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыру | 226 110,87 | 41,0 | уртача еллык контингент, кеше». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының кайбер дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2023 ел, 9 сентябрь, 1116 нчы карары белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының кайбер дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренең норматив чыгымнарындагы 15 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин